РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕВЛАШТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422075 ,Республика Татарстан, Сабинский район, с.Евлаштау, ул. Ш.Бариева, д.23
тел.(84362) 46-8-49

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯВЛАШТАУ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422075, Татарстан Республикасы, Саба районы, Явлаштау авылы, Ш.Бариев урамы, 23 йорт
тел. (84362) 46-8-49

e-mail: Evlash.Sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

25.10.2024 — № 16

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Башкарма комитетының 05.09.2016 елның №35 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

РФ Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 24.10.2022 №1885 карары кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү турында» 05.09.2016 елның №35 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү хакындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.**3.2 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Оешма җитәкчесе янгынга каршы ишекләрне, шулай ук ишек тоткаларын, «антипаник» йозак җайланмаларын, җитештерүче тарафыннан каралган тыгызлауларны һәм ишек бусагаларын, ә баскыч мәйданчыклары ишекләрендә, эвакуацион чыгу ишекләрендә, шул исәптән подвалдан беренче катка алып баручы ишекләрдә (фатирларга, коридорларга, вестибюльләргә (фойе) һәм турыдан-туры тышка алып баручы ишекләрдән тыш) үз-үзен ябу җайланмаларының булуын һәм төзеклеген тәэмин итә.»;

**1.2.**3.2 Пунктта түбәндәге эчтәлекле өченче абзац өстәргә:

«Янгынга каршы яки төтенгә каршы ишекләрне (җайланмаларны) нормаль ябуга комачаулый торган нинди дә булса җайланмалар урнаштыру рөхсәт ителми.»;

**1.3.**4.2 Пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Эвакуация юлларындагы ишекләр, янгын куркынычсызлыгы норматив документлары таләпләре буенча ачылмый торган ишекләрдән тыш, бинадан чыгу юнәлешендә дә иркле ачылырга тиеш.

Катлы коридорлардан, холллардан, фойелардан, вестибюльләрдән, баскыч мәйданчыкларыннан, зал бүлмәләреннән эвакуацион чыгу ишекләрендәге бикләр(йозаклар), биналарны карап тотуның (саклау, иминлекне тәэмин итүнең) махсус

режимы билгеләнгән саклау объектларыннан тыш, аларны эчтән ачкычсыз ирекле ачу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

Биналарны карап тотуның (саклауның, иминлекне тәэмин итүнең) махсус режимы билгеләнгән, мондый биналарның ишекләрен эчтән ачарга мөмкинлек бирми торган саклау объектлары өчен бинаның янгыннан саклау системалары сигналы буенча һәм (яисә) тәүлек буе сак белән шөгыльләнүче хезмәткәр (эшче) тарафыннан эвакуацион чыгу ишекләренең бикләрен автомат рәвештә ачу тәэмин ителергә тиеш.»;

**1.4.** 5.12 пунктының икенче җөмләсендә «янгын щитларының кирәкле саны һәм аларның тибы билгеләнә» сүзләрен «янгын щитларының тибы билгеләнә» сүзләренә алмаштырырга;

**1.5.** 5.13 пункт һәм 5.14 пунктны юкка чыгарырга;

**1.6.** 5.15 пунктны 5.13 пункт дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/evlashtay адресы буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Явлаштау авыл
җирлеге Башлыгы Р.Х.Нуриев